КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 сентябрь г.Казань № 833

Татарстан Республикасының дәүләт гомуми белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмалары директорларының тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләренә ай саен акчалата бүләкләү билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының, Байконур шәһәренең һәм «Сириус» федераль территориясенең дәүләт гомуми белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары директорларының тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләренә ай саен акчалата бүләкләү түләүне тәэмин итү өчен Россия Федерациясе субъектлары, Байконур шәһәре һәм «Сириус» федераль территориясе бюджетларына федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2024 елның 30 маендагы 717 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасының дәүләт гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында тәрбия эшенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасының дәүләт гомуми белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмалары директорларының тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләренә аена 5 000 сум күләмендә ай саен акчалата бүләкләү билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне (каларга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасының дәүләт гомуми белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмалары директорларының тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләренә ай саен акчалата бүләкләү түләү турындагы нигезләмәне;

Муниципаль гомуми белем бирү оешмалары директорларының тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләренә ай саен акчалата бүләкләү түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 26 сентябрь, 833 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасының дәүләт гомуми белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмалары директорларының тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләренә ай саен акчалата бүләкләү түләү турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасының дәүләт гомуми белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмалары директорларының тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләренә ай саен акчалата бүләкләү (алга таба шул ук эзлеклелектә – белем бирү оешмалары, директорлар киңәшчеләре, ай саен акчалата бүләкләү) билгеләү, түләү һәм аны туктату шартлары билгеләнә.

2. Айлык акчалата бүләкләү алу хокукына «директорның тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчесе» вазыйфасына кабул ителгән директорлар киңәшчеләре ия.

3. Директорлар киңәшчеләренә ай саен акчалата бүләкләү түләү белем бирү оешмаларының боерыклары нигезендә хезмәт хакын түләү өчен билгеләнгән срокларда башкарыла.

4. Директорлар киңәшчеләренә ай саен акчалата бүләкләү түләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән күләмдә (әмма ике һәм аннан да күбрәк белем бирү оешмасында хезмәт функцияләрен гамәлгә ашырганда директорның бер киңәшчесенә ай саен иң күбе бер акчалата бүләкләү түләү) гамәлгә ашырыла.

5. Бер ай тулысынча эшләмәгән директорлар киңәшчеләренә ай саен акчалата бүләкләү фактта эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә саналган күләмдә түләнә.

6. Ай саен акчалата бүләкләү түләү директор киңәшчесенең йөклелек һәм бала табу буенча ялга, өч яше тулганга кадәр бала карау буенча ялга чыгу чорында белем бирү оешмасының боерыгы чыккан көннән туктатып торыла.

7. Исәпләү хатасы аркасында ай саен акчалата бүләкләү артык түләнү факты ачыкланган очракта, директорлар киңәшчеләре белем бирү оешмасыннан хәбәрнамә алган көннән 30 календарь көн эчендә артык түләнгән акчаны ирекле рәвештә кире кайтара.

8. Ай саен акчалата бүләкләү түләүгә каралган акчаны максатчан файдаланган өчен җаваплылык белем бирү оешмалары җитәкчеләренә йөкләнә.

9. Ай саен акчалата бүләкләү түләү белем бирү оешмасының тиешле боерыгында күрсәтелгән төрле нигезләр буенча «директорның тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчесе» вазыйфасыннан азат ителгән датадан туктатыла.

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 26 сентябрь, 833 нче
карары белән расланды

Муниципаль гомуми белем бирү оешмалары директорларының тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләренә ай саен акчалата бүләкләү түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип муниципаль гомуми белем бирү оешмалары директорларының тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләренә ай саен акчалата бүләкләү түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары (алга таба – муниципаль берәмлекләр) бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирү максатларын, шартларын һәм механизмнарын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәҗбүри социаль иминләштерү буенча Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондларына (мәҗбүри пенсия иминләштерүгә, вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек очрагы һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминләштерү һәм производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү өчен Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына, мәҗбүри медицина иминләштерүгә өчен Мәҗбүри медицина иминияте федераль фондына) күчерелә торган түләүләрне (алга таба – бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәре) исәпкә алып, директорларның тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләренә, аена 5 мең сум исәбеннән чыгып, ай саен акчалата бүләкләү түләүне финанс белән белән тәэмин итү буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында бирелә.

3. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык).

4. Башка бюджетара трансфертлар әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга башка бюджетара трансфертлар бирү өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

Башка бюджетара трансфертларны финанс белән тәэмин итү чыганагы – федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар акчасы.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

муниципаль берәмлектә финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәсе билгеләнә

торган норматив хокукый акт булу;

муниципаль берәмлектә директорның тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчесе ставкалары кертелгән муниципаль гомуми белем бирү оешмалары булу;

башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү.

6. Башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлек бюджетына алу өчен муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты Министрлыкка, билгеләнгән тәртиптә расланган түбәндәге документларны теркәп, башка бюджетара трансфертлар бирү турында ирекле рәвештә язылган заявка (алга таба – заявка) тапшыра:

муниципаль берәмлектә директорның тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчесе ставкалары кертелгән муниципаль гомуми белем бирү оешмалары булу турында мәгълүмат;

муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында директорның тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчесе саны турында мәгълүмат;

муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәсен билгели торган норматив хокукый актыннан өземтә.

Документлар муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан Министрлыкка, «Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте» мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон формада яисә кәгазь чыганакта бирелә.

7. Министрлык:

заявканы кергән көнендә теркәүгә ала;

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән, тапшырылган документларның комплектлылыгын, алардагы мәгълүматның тулылыгын һәм дөреслеген карап тикшерә, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең әлеге Тәртипнең 5 пунктында каралган шартларга туры килүен тикшерә һәм заявка теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә башка бюджетара трансфертлар бирү яисә башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә муниципаль берәмлеккә, «Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте» мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон формада йә заявкада күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә тиешле хәбәрнамә җибәрә йә, заявка кәгазьдә кергән очракта, муниципаль берәмлек тарафыннан вәкаләт бирелгән вәкаләтле затка кәгазь чыганакта хәбәрнамә тапшыра. Башка бюджетара трансферт бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге карар кабул ителгән көннән алып өч календарь көн эчендә муниципаль берәмлеккә тиешле хәбәрнамә җибәрә.

8. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

муниципаль берәмлекнең әлеге Тәртипнең 5 пунктында каралган шартларга туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

муниципаль берәмлек тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.

9. Башка бюджетара трансфертлар бирү, «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасын файдаланып, электрон документ рәвешендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты арасында төзелә торган килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертлар күләме, аларның максатчан билгеләнеше;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләре күрсәткечләре;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;

хисап бирү сроклары һәм формалары;

Министрлыкның Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгына хисаплар җибәрүенә бәйле рәсми сораулар буенча Министрлыкка башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында рәсми сорауда күрсәтелгән срокларда мәгълүмат бирү хакында нигезләмә;

муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең билгеләнгән күрсәткечләренә ирешмәү нәтиҗәләре;

муниципаль берәмлек тарафыннан килешү белән каралган йөкләмәләрнең үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

якларның килешү шартларын бозган өчен җаваплылыгы.

10. Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертлар бүленеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

11. Муниципаль берәмлеккә бирелә торган башка бюджетара трансфертның ($T_{C1i}$) күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$T_{C1i} = T_{Скр} \times H_{C1} \times N_{См} \times S_{Свзн},$$

монда:

$T_{Скр}$ – директорларның тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләренә ай саен акчалата бүләкләү (5 мең сум) түләү күләме (әмма ике һәм аннан күбрәк мәгариф оешмаларында хезмәт функцияләрен гамәлгә ашырганда директорның тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча бер киңәшчесенә ай саен иң күбе бер акчалата бүләкләү түләү);

$N_{См}$ – директорларның тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләренә ай саен акчалата бүләкләү түләнә торган елның айлар саны;

$S_{Свзн}$ – бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминләштерү кертемнәре.

Муниципаль берәмлек ($H_{C1}$) тарафыннан белдерелгән муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында директорларның тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый

берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләренең фаразлана торган саны түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Н_{С1} = Н_{Са} + Н_{С1в},$$

монда:

$Н_{Са}$ – директорларның бер белем бирү оешмасында хезмәт функцияләрен гамәлгә ашыручы тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләре саны;

$Н_{С1в}$ – директорларның ике һәм аннан да күбрәк белем бирү оешмасында хезмәт функцияләрен гамәлгә ашыручы тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү киңәшчеләре саны.

12. Министрлык Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының башка бюджетара трансфертларны бүлү турындагы хокукый акты үз көченә кергән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә килешү проектын муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетларына кул куярга җибәрә.

13. Килешүгә Министрлык тарафыннан муниципаль берәмлекнең башкарма комитетыннан имзаланган килешү алынган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә имза куела.

14. Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе – бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәрен исәпкә алып, директорларның тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләренә, 5 мең сум исәбеннән чыгып, ай саен акчалата бүләкләү түләү саны.

Директорларның тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчеләренә ай саен акчалата бүләкләү түләү белем бирү оешмаларының «директорның тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча киңәшчесе» вазыйфасына кабул ителгән педагогик хезмәткәрләренә бирелә.

15. Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәлелеген бәяләү килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткечләрен һәм агымдагы календарь елы тәмамлану йомгаклары буенча фактта ирешелгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткечләрен чагыштырып карау юлы белән гамәлгә ашырыла.

16. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль район бюджетының бердәм счетына күчерелә.

17. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты Министрлыкка «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт берләштерелгән мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән түбәндәгеләрне тапшыра:

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 7сеннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча финанслашу

максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында бирелә торган хисап;

хисап елыннан соң килә торган елның беренче 10 эш көне эчендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап.

18. Башка бюджетара трансфертлар бирелгән елдан соң килә торган елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган, әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертлар, башка бюджетара трансфертлар бирелгән елдан соң килә торган елның беренче 15 эш көне эчендә, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты керемenә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.

19. Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты һәм вазыйфаи затлар тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары үтәлеше өчен законнар нигезендә җавап бирә.

20. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары һәм башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләренә ирешү йөкләмәләре бозылган очракта, тиешле акча Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемә күчерелергә тиеш. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансферт максатчан файдаланылмау Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын бәхәссез түләтүгә китерә.

21. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны контрольдә тоту законнар нигезендә Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

___